**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

17.03.2016 Яр Чаллы № 652

Тукай муниципаль районында төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча язгы чаралар үткәрү турында

Тукай муниципаль районы территориясенең тиешле санитар, эстетик торышын тәэмин итү һәм аны алга таба төзекләндерү максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2016 елның 1 апреленнән Тукай муниципаль районы территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча икеайлык (алга таба - икеайлык) игълан итәргә.
2. Районда санитар-экологик хәлне яхшырту буенча комплекслы чаралар планын расларга (1 нче кушымта нигезендә).
3. Санитар-экологик чаралар үткәрүне оештыру буенча эшче комиссия составын раслау (2 нче кушымта нигезендә).
4. Авыл җирлекләре башлыкларына авыл җирлекләре территориясендә икеайлыкны оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Барлык милек формасындагы оешма һәм предприятие җитәкчеләренә үз карамагындагы территорияне санитар чистартуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. В. Асылгәрәев